| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 нче август 2014 ел Казан ш. № 10-22/кс

***«Югары Ослан районы коммуналь челтәрләре" ААҖ тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү хезмәтенә тарифны билгеләү турында***

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 30 декабрь, 2004 ел, № 210-ФЗ Федераль закон, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәмә хакларны һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 14 июль, 2008 ел, № 520 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның 1нче кушымтасына туры китереп, «Югары Ослан районы коммуналь челтәрләре» ААҖ тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү хезмәтенә тарифны календарь бүленеше буенча билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 1нче октябреннән 2017 елның 31 декабренә кадәр үз көчендә була.
3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына, 2нче кушымтага туры китереп, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә коммуналь комплекс оешмалары производство программаларының төп күрсәткечләрен килештерергә.
4. «Югары Ослан районы коммуналь челтәрләре» ААҖнә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30 декабрь, 2009 ел, № 1140 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
5. Әлеге карарда билгеләнгән каты көнкүреш калдыкларын утильләштерүгә һәм күмү хезмәте күрсәтүгә тариф «Коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийлары системасын билгеләү турында» 24 февраль, 2014 ел, № 56 Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары

товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15 августа 2014 г. № 10-22/кс
карарына № 1 кушымта

## «Югары Ослан районы коммуналь челтәрләре” ААҖ тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү хезмәтенә тарифлар, календарь бүленеш белән

| № п/п | Муниципаль берәмлек, коммуналь комплекс оешмасы атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерүгә һәм күмүгә тарифлар, сум/куб.м | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 елның 1нче октябреннән 2014 елның 31нче декабренә кадәр | 2015 елның 1нче гыйнварыннан 2015 елның 30нчы июненә кадәр | 2015 елның 1нче июленнән 2015 елның 31нче декабренә кадәр | 2016 елның 1нче гыйнварыннан 2016 елның 30нчы июненә кадәр | 2016 елның 1нче июленнән 2016 елның 31нче декабренә кадәр | 2017 елның 1нче гыйнварыннан 2017 елның 30нчы июненә кадәр | 2017 елның 1нче июленнән 2017 елның 31нче декабренә кадәр |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Югары Ослан районы коммуналь челтәрләре” ААҖ* | 114,34 | 114,34 | 125,34 | 125,01 | 125,01 | 125,01 | 135,13 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15 августа 2014 г. № 10-22/кс
карарына № 2 кушымта

# Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә «Югары Ослан районы коммуналь челтәрләре” ААҖ производство программасының төп күрсәткечләре

| Коммуналь комплекс оешмасы атамасы | 2014 елның 1нче октябреннән 2014 елның 31нче декабренә кадәр | | | | | 2015 елның 1нче гыйнварыннан 2015 елның 31нче декабренә кадәр | | | | | 2016 елның 1нче гыйнварыннан 2016 елның 31нчы декабренә кадәр. | | | | | 2017 елның 1нче гыйнварыннан 2017 елның 31нчы декабренә кадәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Коммуналь комплекс оешмасының производство программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сум. (ӨБСсыз) | Коммуналь комплекс оешмасының производство программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сум. (ӨБСсыз) | Коммуналь комплекс оешмасының производство программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сум. (ӨБСсыз) | Коммуналь комплекс оешмасының производство программасы күрсәткечләре, мең.куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сум. (ӨБСсыз) |
| | Утильләштерелгән һәм күмелгән каты көнкүреш калдыклары күләме, шул исәптән: | | | | | Утильләштерелгән һәм күмелгән каты көнкүреш калдыклары күләме, шул исәптән: | | | | | Утильләштерелгән һәм күмелгән каты көнкүреш калдыклары күләме, шул исәптән: | | | | | Утильләштерелгән һәм күмелгән каты көнкүреш калдыклары күләме, шул исәптән: | | | | |
| | Барлыгы | Халык | Бюджеттан кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджеттан кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджеттан кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджеттан кулланучылар | Башка кулланучылар | |
| «Югары Ослан районы коммунал ь челтәрләр е” ААҖ* | 29,44 | 0 | 0,27 | 29,17 | 3093,62 | 29,44 | 0 | 0,27 | 29,17 | 3241,98 | 29,44 | 0 | 0,27 | 29,17 | 3381,51 | 29,44 | 0 | 0,27 | 29,17 | 3517,83 |

<*>өстәмә кыйммәткә салым түләүче булып тормый

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге